# Тарих битләрен барлаганда...

## Төрле елларда эшләгән житәкчеләр

| Мәктәп статусы | Фамилия, исем | Еллар |
|---|---|---|
| Башлангыч | Кадыйров Әмирҗан (гарәп графикасы) | 1927-1929 |
| | Шәрипов Әмирҗан (Теләнчедән) | 1930-1931 |
| | Шәйхеталип | 1932-1933 |
| | Кирамов | 1933-1934 |
| | Гафурова Шәмсия | 1934-1935 |
| 7 еллык мәктәп | Мозаффаров | 1935-1936 |
| | Мусин Лотфулла | 1936-1937 |
| Урта мәктәп | Бариев Шәех | 1938-1939 |
| | Гыйлаҗин | 1940-1941 |
| | Галиев | 1941-1942 |
| | Вәлидова Разия | 1942-1943 |
| | Шакиров Шамил | 1943-1944 |
| | Бариев Әнвәр | 15.08.1945-20.11.1945 |
| | Газизов Мирза | 1946-1947 |
| | Юнусов Һарун-Рәшит | 1947-1948 |
| | Әгъләмов Миңнулла | 1948-1951 |
| | Мәйлүнов Мирзаһит | 1951-1957 |
| | Әхмәтов Хәмит | 1958-1961 |

# Вәлиев Сәйдел Кәнделәсрар улы



Вәлиев Сәйдел Кәнделәсрар улы 1923 нче елның 25 нче ноябрендә элекке Уфа губернасы, Минзәлә өязе, Әмәкәй волостена кергән Күбәк авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1930-1940 нчы елларда шул авылда башлангыч мәктәпне, аннары тулы булмаган урта мәктәпне, 1938-1941 нче елларда урта мәктәпне тәмамлый.

1941 нче елның сентябреннән 1942 нче елның май аена кадәр “Кызыл Сабанчы” колхозында табельчик-кассир, аннары хисапчы булып эшли.

1942 нче елның май аеннан 1942 нче елның 1 нче декабренә кадәр кызылармеец булып хезмәт итә.

1942 - 1945 нче елларда Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыш тәмамлангач та,2 елга якын Германия һәм Көнбатыш Польша җирендә армия сафларында була. 1947 нче елның 7 нче апрелендә генә туган якларга әйләнеп кайта. Күбәк җидееллык мәктәбенә рус теле һәм әдәбияты укытучысы итеп билгеләнә.

1947 нче елның сентябреннән 1957 нче елның гыйнварена кадәр Күбәк урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта. Читтән торып Алабуга укытучылар, ә 1957 нче елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый.

1957 - 1958 нче елларда партия оешмасы секретаре булып эшли.

1959 – 1960 һәм 1962-1967 нче елларда - Күбәк урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы һәм укыту бүлеге мөдире.

1967 - 1969 нчы елларда - Мөслим районы Үрәзмәт урта мәктәбе директоры һәм тарих укытучысы.

1969 – 1970 нче елларда Куйбышев исемендәге колхозда партия оешмасы секретаре вазифаларын башкара.

1970-1983 нче елларда Күбәк урта мәктәбендә директорлык эшен алып бара,уку-укыту бүлеге белән җитәкчелек итә, тарих һәм география фәннәрен укыта.

1984 нче елдан - лаеклы ялда. 1988 нче елга кадәр мәктәптә дәресләр алып бара.



# Вәлиев Зәйнәгытдин Вәҗи улы

Вәлиев Зәйнәгытдин Вәҗи улы 1931 нче елда Мөслим районы Бәкәбез авылында туа. 1932 нче елда аларның гаиләсе яңа төзелә торган Коммуна авылына күчеп китә һәм аның балалык еллары да шул авылда үтә. Күбәк урта мәктәбендә белем ала.

Минзәлә педагогия училищесын тәмамлаганнан соң, үзе укыган Күбәк мәктәбендә рус теле һәм математика фәннәрен укыта. Төрле елларда, читтән торып, ике югары белем ала. З. Вәлиев 1964-1972 нче елларда 12 авылны берләштергән Куйбышев исемендәге колхозда партком секретаре һәм колхоз рәисе булып эшли.

1972 нче елдан бирле аның хезмәт юлы мәгариф системасы белән бәйле.

7 ел Күбәк урта мәктәбендә директор вазифасын башкара.

1978-1983 нче елларда – Мөслим районы мәгариф бүлеге мөдире, 1983-1995 нче елларда – Күбәк урта мәктәбе директоры, 1995 нче елдан – ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының фәнни-методик үзәгендә барлык төр уку йортлары өчен программалар, дәреслекләр, укыту-методик әдәбият чыгару мөдире булып эшли. Аның күпсанлы фәнни-методик һәм публицистик мәкаләләре вакытлы матбугат битләрендә дә басылып чыга. Якташыбыз – спорт мастерлыгына кандидат, ике тапкыр Татарстан укытучылары съезды, бер мәртәбә Бөтенсоюз укытучылары съезды делегаты була.

Зәйнәгытдин Вәҗиевичның күпьеллык намуслы хезмәте югары бәяләнә. Аның “РСФСРның халык мәгарифе отличнигы”, “Югары категорияле укытучы”, “Татарстанның атказанган укытучысы” дигән мактаулы исемнәре бар.

З. Вәлиевны үзенең гомерен иң мактаулы һәм күпкырлы тәрбия эшенә биргән үзенчәлекле, эзләнүчән һәм таләпчән педагог буларак беләләр. Югары әхлак сыйфатларына ия булган намуслы, гади һәм тыйнак якташыбыз кайда гына эшләсә дә, үз-үзенә һәм башкаларга карата таләпчән җитәкче, оста оештыручы буларак таныла.



## Галиев Диктат Әхмәтгали улы

Диктат Галиев 1934 нче елның 8 нче мартында Иске Карамалы авылында колхозчы гаиләсендә туа.

Минзәлә педагогия көллиятен уңышлы тәмамлаганнан соң, Алабуга дәүләт педагогия институтында белем ала.

1957-1960 нчы елларда Күбәк урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты фәннәрен укыта.

1960-1970 нче елларда мәктәп директоры булып эшли.

1970-1984 нче елларда - КПСС райкомының икенче секретаре, бер ел халык депутатларының район Советы башкарма комитеты рәисе вазыйфаларын башкара.

Кама автомобиль заводында двигательләр ремонтлау заводы директоры урынбасары булып эшләгәннән соң, 1986-1996 нчы елларда Яр Чаллы шәһәрендәге 13 нче санлы мәктәпне җитәкли.

2004 елга кадәр Казанда мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү институтында укыта.

Татарстанның атказанган укытучысы, РСФСРның халык мәгарифе отличнигы.

Диктат Галиев кайда гына эшләсә дә, хезмәтенә бирелгәнлеге, грамоталылыгы, таләпчәнлеге, төгәллеге, кешелеклелеге белән аерылып тора. Районыбызның социаль-икътисадый үсешенә үзеннән зур өлеш керткән, туган төбәге, халкы өчен янып-көеп яшәгән шәхесләрнең берсе ул.



## Исламов Альберт Хәким улы

Исламов Альберт Хәким улы 1954 нче елда Татарстан Республикасының Мөслим районы Бүләк авылында хезмәткәр гаиләсендә туа.

Урта мәктәпне тәмамлагач, 1971-1973нче елларда Түбән Кама шәһәрендә ГПТУ - 44тә белем ала.

1973-1975 нче елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.

1976-1977 нче елларда Күбәк урта мәктәбендә география, 1978-1981 нче елларда Татар Бүләре урта мәктәбендә машина белеме (“Машиноведение”) укыта.

1976-1981 нче елларда, читтән торып, Казан дәүләт университетының тарих факультетында белем ала.

1986 нчы елдан Күбәк урта мәктәбендә тарих укытучысы һәм укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшли.

1995 нче елдан 2008 нче елга кадәр мәктәп директоры вазифасын башкара.

Хәзерге вакытта лаеклы ялда.

# Мөхәмәдиева Ләйсинә Расил кызы



Мөхәмәдиева Ләйсинә Расил кызы 1965 нче елның 12 нче августында Мөслим районы Яңа Сәет авылында туа. Башлангыч белемне Яңа Сәет авылында ала, Татар Бүләре урта мәктәбендә укуын дәвам итә. Урта мәктәпне “4”ле, “5”ле билгеләренә генә тәмамлый.

1982 нче елда Казан дәүләт педагогия институтының физика - математика факультетына укырга керә. Хезмәт юлын 1986 нчы елда Метрәй урта мәктәбендә башлый.

1987-1989 нчы елларда Күбәк урта мәктәбендә математика фәнен укыта һәм пионервожатый булып эшли. Шул ук вакытта мәктәптә комсомол секретаре вазифасын да башкара. Авыл яшьләре белән күңелле очрашулар, КВНнар үткәрә.

1989 нчы елда район комсомол комитетының IIсекретаре итеп сайлана.

1991-1995 нче елларда Октябрь урта мәктәбендә математика укытучысы һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшли. 1995-2004 нче елларда Күбәк урта мәктәбендә математика фәнен укыта.

2004-2009 нчы елларда “Наз” социаль приютында директор вазифасын башкара.

2009 нчы елдан бүгенге көнгә кадәр Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбендә директор булып эшли һәм математика фәнен укыта.